КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 16 август г.Казань № 982

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә кую турында» 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмалары студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә кую турында» 2016 ел, 20 сентябрь, 660 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 май, 338 нче; 2020 ел, 2 октябрь, 901 нче һәм 2021 ел, 27 гыйнвар, 29 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирә торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлек төрен күздә тоткан югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча укучы студентларына стипендияләр рәвешендә айлык түләүләр бирү кагыйдәләрендә:

3 пунктның өченче абзацында «укучы килешүендә» сүзләрен «максатчан укыту турындагы килешүдә» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктның беренче абзацында «, әмма кимендә 190 балл» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта «Министрлык тарафыннан раслана торган форма буенча укучы килешүләре» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган бертип форма буенча максатчан укыту турындагы килешүләр» сүзләренә алмаштырырга;

19 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Кагыйдәләрнең 13 пунктының өченче, бишенче абзацлары, әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктында билгеләнгән нәтиҗәләр нигезендә стипендияләр түләү туктатылган затларны түбәндәге арадаш аттестацияләү нәтиҗәләренә туры килгән һәм стипендиягә хокук торгызылган очракта элек бирелгән стипендия суммасын кире кайтару гамәлгә ашырылмый. Студент Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хезмәткә чакырылуга, шул исәптән мобилизация буенча, бәйле рәвештә уку йортыннан киткән очракта стипендия түләү туктатылганда, аны алга таба Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хезмәт узу, шул исәптән мобилизация буенча, тәмамланганнан соң югары белем бирү оешмасына торгызганда һәм арадаш аттестацияләү йомгаклары әлеге Кагыйдәләрнең 4 пунктында билгеләнгән нәтиҗәләргә туры килгәндә, элегрәк бирелгән стипендия суммасын кире кайтару гамәлгә ашырылмый.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларына эшчәнлекнең педагогик төрен күздә тота торган югары белем бирү мәгариф программалары буенча стипендияләр рәвешендә айлык түләүләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

$5^1$ пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«студент, югары белем бирү оешмасы һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башкарма комитеты арасында төзелгән максатчан укыту турындагы килешүләр булу.»;

3 пунктның өченче абзацында «укучы килешүләре» сүзләрен «максатчан укыту турындагы килешүләр» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип формасы нигезендә Министрлык һәм башкарма комитет арасында төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү (алга таба - килешү) нигезендә бирелә.

Килешүдә башка бюджетара трансфертлар күләме, аларның максатчан билгеләнеше, башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре, башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе, финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында хисаплылык тапшыру сроклары һәм рәвешләре, аларны ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт һәм йөкләмәләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында, килешүдә каралган йөкләмәләрне алучы тарафыннан үтәүне тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе, килешүнең шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы каралган.»;

11 пунктта:

беренче абзацта «Файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре» сүзләрен «Бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта:

беренче абзацта «Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча башка бюджетара трансфертлардан файдалану турында һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләренә ирешү турында хисап» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән килешүнең бертип рәвешенә теркәлгән формалар буенча финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгымнар турында һәм аларга ирешү максатларында кабул ителгән башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү хакында хисаплар» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәләре) күрсәткечләре» сүзләрен «башка бюджетара трансфертлар бирү нәтиҗәләре» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «башка бюджетара трансфертдан файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече» сүзләрен «башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга;

уникенче абзацта «башка бюджетара трансфертдан файдалануның нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече» сүзләрен «башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин